ЕРАКТАГЫ МӘКТӘП

«Мобиль укытучы» грантын отучыларга машина бирелә

> 2

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

Әдәби бәйгеләрнең әһәмияте әйтеп бетергесез

> 3

ӘНИ ТЕЛӘГЕ

РСФСРның спорт мастеры Илдар Рәфыйковның нинди үкенече калган?

> 4

БЕРЕНЧЕ СӘХНӘ

«Апуш» татар театр студиясе балалар сәнгатенә, иҗатына сукмак сала

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 149 (28922) | Сишәмбе | 11 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТИР БӘЯСЕ

АВЫЛ ХЕЗМӘТЧӘННӘРЕ ҺӨНӘРИ БӘЙРӘМНӘРЕН БИЛГЕЛӘП УЗДЫ

Игенчегә хөрмәт, аларны кадерләү турында әледән-әле сөйлибез. Хезмәт кешесе аны сизәме? Авыл хезмәтчәннәренә хөрмәт нидә чагыла? Әлеге гади, шул ук вакытта җитди сорауга җавапны без кырда, фермада алны-ялны белмичә эшләүче кешеләр белән бергәләп эзләдек.

Иң элек без сорауны шушы көннәрдә Россиянең авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев кулыннан Россия Хөкүмәтенең Рәхмәт хатын алган Азат Шакировка бирдек. Яшь кенә булуына карамастан (Азатка – 29 яшь), шундый зур игътибарга һәм хөрмәткә ия булган Кукмара районы механизаторы бу вакыйганы «һич көтелмәгән, әмма хезмәтемә иң зур бүләк» дип бәяләде.

– Мин кечкенәдән бирле авыл хуҗалыгына тартылдым, ә ныклап торып эшли башлавыма – сигезенче ел. Елның кайсы гына фасылына карамастан, мин – трактор рулендә. Һич икеләнми, мин үз урынымда, дип әйтә алам, – дип, үзе белән таныштырды ул. – Мәскәүгә бару көтелмәгән хәл булды. Казанда «Профессиядә иң яхшысы» дигән ярышта катнашкан идем. Шуннан соң документларымны Мәскәүгә җибәргәннәре билгеле булды. Министр кулыннан шундый зур мактау кәгазе алу туган көнемә иң көтелмәгән бүләк булды. Бу хакта хәтта хыялланганым да юк иде.

Билгеле, хезмәт кешесенә хөрмәт мактау кәгазьләре алуда гына чагылыш тапмый, дип саный ул.

– Анысы да – күңелне күтәрә, үсендерә торган күренеш, әлбәттә. Илебезгә файдалы эш белән шөгыльләнүебез өчен тагын бер кат горурланыр өчен форсат. Тик боларга өстәп, лаеклы хезмәт хакы, эшләргә мөмкинлекләр дә кирәк. Авылда киләчәкләрен авыл хуҗалыгы белән бәйләгән яшь гаиләләргә, аларның балаларына яхшы шартлар тудыру да – хөрмәт билгесе. Ә инде бүген мин хезмәттәшләремә саулык, гаилә бәхете һәм, әлбәттә, тынычлык телим, – диде Азат.

Тәҗрибәле фермер, авыл хуҗалыгы тармагының «аксакал»ы Минталип Минехановның да фикерен беләсебез килеп шалтыраттык. Ә ул, нинди бәйрәм, без эштә бит, дип көлеп җибәрде.

– Авыл хезмәте ул – безнең яшәү рәвеше, шуңа күрә безгә бәйрәме дә юк аның, – диде ул. – Авылга кагылышлы Сабан туенда да күпчелек очракта шәһәр халкы ял итә, крестьян эштә кала. Менә хәзер көнаралаш яңгыр яуды. Бераз киптереп җибәргәч, кырга кереп киттек, чөнки бәрәңгене алып бетерәсе бар. Безнең бөтен уебыз кырдагы уңышны җыеп алып, кешеләрнең табынына ризык итеп җиткерү тирәсендә бөтерелә. Менә бу – безгә, чыннан да, бәйрәм. Икенчедән, авыл хуҗалыгына ярдәм күрсәтә торган субсидияләрне вакытында түләсәләр, шулай ук бәйрәм булыр иде. Бәйрәмендә ашап-эчеп йөри алмасак та, икенче икмәк, яшелчәләр үстерә, аларны балаларга илтеп җиткерә алабыз, дип горурланабыз. Бу эшләрне башкара алу да – үзе бер бәйрәм безгә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Минталип Минеханов әйтүенчә, авылда эшләүчеләргә лаеклы хезмәт хаклары түләнергә тиеш. Икенчедән, кадрлар мәсьәләсенең бик җитди дәрәҗәдә хәл ителүен тели ул. Яхшы орлыклар алуда, складлар булдыруда ярдәм булса да, эш кешесенә хөрмәтне күрсәтер иде, дип саный фермер.

Әлмәт районының Бишмунча авылында яшәүче Мостафиннар – гаиләләре белән авыл хуҗалыгында тир түгүчеләр. Әтиләре Марат абый – алдынгы механизатор, әниләре Лениза апа гомере буе сыер савучы булып эшләгән. Хәтта уллары һәм ике кызлары да комбайн иярләгән тырыш, булдыклы гаилә. Алар хөрмәт тоямы соң?

– Игенчеләргә дә, терлекчеләргә дә хөрмәт булмады, дип берничек тә әйтә алмыйм, – диде Лениза апа. – Колхоз рәисе Минфаязның ярдәмен һәм ихтирамын һәрвакыт тоеп эшләдек. Марат быел кулын авырттырган иде, шулай булуына карамастан, булышмыйча ярамый дип, комбайнга утырды. Әле дә ашлык җыюдан кайтып кергәне юк. «Атказанган механизатор» исемен дә бирделәр үзенә. Премияләрен Марат та, балалар да яхшы алып барды. Үзем дә, эшләгән чакта, игътибардан читтә калмадым. Акчаларын биреп бардылар, ярышларга йөртеп тордылар. Димәк, район да ышанган бит. Зур урыннар алмасак та, бүләкләрен мулдан бирәләр иде. Әгәр хуҗалыктан акчалата, ашлыклата, печәнләтә ярдәм булмаса, тугыз баш сыер да асрый алмаган булыр идек. Без бер дә зарлана алмыйбыз. Хезмәт кешесен кимсетүне сизмәдек. Әле дә агрофирмаларның эшчәнлекләрен күзәтеп торам, андагы шартлар эшләр өчен начар дип әйтмәс идем. Эшче өчен анысы да мөһим. Хөрмәт дигәндә мин менә шушыларны күзаллыйм.

Хәтерләсәгез, ел башында газетада «Апас-мол» агрофирмасы эшчеләренең хезмәт хакларын тотып калулары турында язма басылган иде. Безне кызыксындырган сорауны язмабызның герое – егерме ел терлекче булып эшләгән Люция Сәлаховага да бирергә булдык.

– Хезмәт кешесенә хөрмәт турында сөйләргә дә кирәкми. Безне белгән кеше дә юк, – диде ул. – Хезмәт хаклары буенча үз фикеремне әйткәч, бөтенләй эштән кудылар. Минем артымнан тагын берничә кешене җибәрделәр. Колхоз вакытында игътибар булды әле. Бүләген дә, акчасын да алдык. Хәзер дә, агрофирмада эшләгән вакытта да андый хөрмәт күргән булмады.

Хезмәт кешесе кайда да шул ук эшне эшли югыйсә. Тик, күрәсең, хөрмәте генә төрле җирдә төрлечә...

Сөйләнү түгел

2022 елның сигез аенда Татарстанда барлыгы 16301 никах теркәлгән. «Росстат» статистика хезмәте мәгълүматларына караганда, бу сан, узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, нибары 1 процентка кимрәк.

Бу елның гыйнвар – август айлары аралыгындагы нәтиҗәләргә караганда, Татарстан гаилә төзүчеләр саны буенча Идел буе төбәкләре арасында – беренче урында. Башкортстан – икенче. Күрше республикада 15309 никах теркәлгән. Өченче урында – Түбән Новгород өлкәсе (13060). Мари Илендә исә нибары 1928 пар никахын рәсмиләштергән. Бу – Идел буе төбәкләре арасында иң түбән күрсәткеч.

Бушлай йөриләр

Мобилизацияләнгән кешеләрнең балалары 10 октябрьдән Казан җәмәгать транспортында бушлай йөри алачак. Бу хакта шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илдар Шакиров хәбәр итте. «Махсус документ 8 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар өчен барлык төр җәмәгать транспортында да бушлай йөрү хокукы бирә», – дип аңлатты ул.

Бу мөмкинлектән файдалану, ягьни махсус карта алу өчен, бала белем ала торган мәктәпкә тиешле гариза белән мөрәҗәгать итәргә кирәк. Гариза янында мобилизацияләнгән кеше белән туганлыкны раслый торган документ та булырга тиеш. 10 октябрьгә Казанда 300ләп шундый карта әзерләнгән инде.

Рухлары сау булсын

Татарстанда психологик ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләрнең саны арткан. Узган ел мондый мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны 32 меңләп булса, 2022 елның тугыз аенда инде 30 меңләп кеше ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән. Бу хакта «Ышаныч» балалар һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәгендә Татарстанның яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов хәбәр итте. Дөнья күләмендә уздырыла торган психологик ярдәм күрсәтү көнендә Татарстанда яшьләр өчен бердәм ышаныч телефоны барлыкка килде. Психологик ярдәм кирәк булган чакта, 14 яшьтән алып 35 яшькә кадәрге татарстанлылар хәзер 8-800-555-22-20 телефонына шалтырата ала. Аларга профессиональ психологлар ярдәм итәчәк.

Авыручылар кими

Татарстанда 3 октябрьдән 9 октябрьгә кадәр коронавирус белән авыруның 2413 очрагы ачыкланган. Коронавирус таралуга каршы федераль оператив штаб мәгълүматларына караганда, бу – узган атнадагы саннарга караганда 40 процентка кимрәк дигән сүз. 26 сентябрьдән 2 октябрьгә кадәр республикада коронавирус белән авыручы 4008 кеше ачыкланган иде.

Сүз уңаеннан, Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко күпчелек төбәкләрдә коронавирус белән авыручыларның кимүен, әмма вазгыятьнең элеккечә киеренке булуын искәртте.

Соңгы мәгълүматларга караганда, Татарстанда коронавирус йоктыруның барлыгы 183147 очрагы теркәлгән.

Һава торышы

Җылы көтәбезме?

Әбиләр чуагын көтмәгез инде! Казан федераль университеты профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев әнә шулай ди.

– Гадәттә әбиләр чуагы, сентябрь уртасында булып, берәр атна дәвам итә иде. Әмма быел ул булмады. Шуңа күрә аны көтүдән мәгънә дә юк. Дөрес, матур көннәр булыр әле. Әмма кояш артык иркәләмәс, – ди ул. – Әлегә температура нормадан 2–3 градус югарырак. Явым-төшемнәр юк. Әмма чәршәмбе кичтән кинәт кенә һава торышы үзгәрәчәк. Көньяктан циклон килә. Шуннан соң көннәр суытып җибәрәчәк.

Халык синоптигы, Балтач районының Яңгул авылында гомер итүче Әмир Шәрәфиев исә көзнең яңгырлы, юеш буласына өметләнә. Аның фикеренчә, җиргә җылы түгел, дым кирәк.

– Дүрт ел инде җиргә җитәрлек яңгыр яуганы юк. Җир асты сулары белән өскесе тоташа алмый. Быел исә өмет бар. Күзәтүләремнән чыгып, шуны әйтә алам: быел көз яңгырлы булачак, – ди синоптик. – Әбиләр чуагына килгәндә, ул берничә өлешкә бүленде. Берничә көн белән туктады. Инде хәбәр иткәнемчә, быел яз да ике атнага соңга калып килде бит. Хәтерләсәгез, февраль белән мартның урыннары да алышынып торды. Май ае да җитәрлек булмады. Март аның өлешенә дә керде. Шулай итеп, җәй дә ике атнага соңарып килде. Күпләребез, уңыш булмас, дип борчылган иде. Чынлап та, быел печән дә үсмичә торды бит. Әмма көннәр җылытып җибәргәч, бер атна эчендә күтәрелде дә куйды.

Әмир Шәрәфиев әйтүенчә, чын әбиләр чуагы симәнә көнне, 14 сентябрьдә башланырга тиеш булган. Әмма ул вакытта матур көннәр булмады. Хәзерге матур көннәр дә санаулы гына, ди ул.

– Агач яфраклары әле генә саргая башлады. «Алтын көз»не яңа күзәтәбез. Елдан зарлана торган түгел. Авыл хуҗалыгы өчен бик уңышлы булды. Җиргә дым да төште. Иген дә, бәрәңге дә уңды бит. Алмагачлар сыгылып утырды. Хәзер барысына да су кирәк. Үзең сибеп кенә аларга җитми ул. Яңгыр көтәбез. Әле ул күп явачак. Җирдә дә җитәрлек дым булыр, дип уйлыйм, – ди Әмир абый. – Беренче кырау 5 сентябрь көнне төште. Ә менә беренче кар күренми әле. Башка елларда бу вакытта кар күрсәтә иде инде. Кыш та соңга кала. Беренче кар төшеп, 6 атна узгач кына кыш җитәчәк. Декабрьнең яртысы җылы булыр. Ә менә калган айлар салкын киләчәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КӨЗГЕ СЫНАМЫШЛАР

- Кояш батканда аяз булып, төньяктан салкынча җил булса, кырау төшәр.
- Көз озын килсә, яз соң килер.
- Көзнең ахырында вак кына түгәрәк-түгәрәк боз яуса, кыш суык булыр.
- Имәндә чикләвек күп булса, кыш салкын килә.
- Урманда чикләвек күп булса, кыш кырыс булачак.
- Чия яфраклары коелып бетми торып, кар, күпме яуса да, барыбер эреп бетә.
- Кыр казлары иртә китсә, кыш иртә килә.
- Кыр казлары көзен түбәннән очып китсәләр, кар тиз булыр.
- Көз көне куяннар бер эздән йөрсә, кыш көне кар күп явар.
- Тычканнар, күселәр ояны тирән казыса, кыш суык булыр.
- Умарта кортлары ояда яфракларны калын сыласа, кыш салкын була.

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Шулай итеп, Киев режимы гамәлләре белән үзен халыкара террорчылык оешмалары, иң начар төркемнәр белән бер дәрәҗәгә куйды. Мондый җинаятьләрне җавапсыз калдыру берничек тә мөмкин түгел. Безнең территориядә теракт уздыру омтылышлары дәвам иткән очракта, җавабы каты һәм Россиягә янаган куркыныч дәрәҗәсендә булачак. Моңа беркемнең дә шиге булмасын.

(Иминлек Советының даими әгъзалары белән киңәшмәдән)

РАЙОН ҺӘМ ШӘҺӘРЛӘР РЕЙТИНГЫ

Татарстанның Икътисад министрлыгы республика районнары һәм шәһәрләренең гыйнвар–август айларына социаль-икътисади үсеш рейтингын игълан итте.



1.......................>>Лаеш
2....................>>Әлмәт
3....................>>Казан
4............>>Түбән Кама
5....................>>Тукай

41...................>>Спас
42................>>Теләче
43..............>>Чүпрәле
43.......>>Кама Тамагы
43................>>Әгерҗе

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 3–13 октябрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — **Ташламалы бәя** 444 сум 54 тиен, гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** 980 сум 10 тиен, гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Реклама 16+

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АЛДА НИ КӨТӘ?

Инглиз телле The Economist атналыгы үзенең соңгы тышлыгын үзәккә «Алда ни көтә?» дигән сорау куйган рәсем белән бастырды. Сынып беткән кызыл графиклар өстендә – Азиягә карап баскан кыз рәсеме. Графикларның үрле-кырлы сикерүен икътисади түнтәрелеш дип аңлап була.

Рәсемнең символик мәгънәсен кем ничек теләсә, шулай аңлата ала, билгеле. Әмма The Economistтан башка да планетадагы хәлләрнең начар икәнлеген барыбыз да беләбез. Вакыйгалар шулкадәр кызу әйләнә: кайсын тотып алып, алгы планга чыгарырга белмәссең. «Атом-төш армагеддоны янавы Кеннеди заманнарыннан һәм Кубадагы ракета кризисыннан соң беренче тапкыр яңадан әйләнеп кайтты», – дип белдерде Америка Президенты Байден. Ихтимал, бу көннәрнең иң зур проблемасы шулдыр. Эш җитди. Матди кыенлыкларга түзеп була, алар кайчан да булса бер уза. Мәйданга атом-төш катастрофасын тартып кертү зур һәлакәт вәгъдә итә. Әмма икътисади түнтәрелеш белән зур конфликтта бар нәрсәнең дә янып бетүе – үзара тыгыз бәйләнгән нәрсәләр. Халыкара финанс мафиясе зур сугышны икътисади түнтәрелешкә китергән сәбәп итеп күрсәтергә омтыла. Русларда «война все спишет» дигән сүзләр бар бит әле. Менә шул кагыйдәне файдаланырга телиләр.

Кризис исә бөтен почмаклардан бәреп керә. Америкада фонд базарлары кызыл төстә, ягъни котировкалар түбәнгә оча. Франциядә автозаправкаларның 20 проценты ягулык дефициты кичерә, дип яза Le Figaro. Әйе, ягулык кризисы Көнбатышта кискен тора. ОПЕК+ның «кара алтын» чыгаруны 2 миллион баррельгә киметү туында сүз алып баруын американнар үз яңакларына сугу кебек кабул итте. Әр-Рияд белән Вашингтон арасында зур конфликт туып килә. Дөнья сәясәтенең шахмат тактасында позицияләр бөтенләй гаҗәп. Кайчандыр Вашингтон сүзеннән бер дә чыкмаган гарәпләр Россия ягына таба авыша, Кытай белән стратегик аркадашлык корып яталар. Әйтик, Россияне нефть базарыннан этеп чыгара алсалар, гарәпләргә икеләтә файда бит: баррель бәясе дә югары торачак, базарда җир маен да күпләп сатачаклар. Ләкин Якын Көнчыгышның нефть державалары ул мөмкинлектән файдаланырга теләми. The Washington Post газетасына Ак йортның бер чиновнигы ОПЕК+ карарын «катастрофа» дип бәяләде.

Катастрофа «кара алтын» кытлыгы белән төгәлләнми. Ул аеруча финанслар өлкәсендә яхшы чагыла. АКШның дәүләт әҗәте тарихта беренче тапкыр 31 триллион доллардан артып китте. Бу түләп була торган акча түгел. Европада да шул ук хәл. Акча станогын бар көченә эшләтсәң дә җиткерә торган түгел. Польша Премьеры акча табуның җиңел ысулын тәкъдим итә: туңдырылган 350 миллиард долларлык Россия активларын Украина һәм Европа Союзы арасында бүлешик, ди.

Акча кытлыгы кичерүче Ливанда халык банкларга салган акчаларын кире кайтаруның гади ысулын уйлап тапты. Коралланып, банкларга керәләр дә үз акчаларын түләүне таләп итәләр. Бирми кара. Банклар исә бу афәттән барысы берьюлы вакытлыча ябылып котылырга булдылар.

Россиядә

ЭШЛӘГӘН ПЕНСИОНЕРНЫҢ АКЧАСЫН БИРЕГЕЗ

Кызганыч, Кырым күперендә булган хәлләр Россиянең зур конфликт үзәгендә торачагын һәм алдагы айларда һәм атналарда булырга мөмкин булган бөек вакыйгалар безнең барыбызга да турыдан-туры кагылачагын аңлата.

Әлегә без, икътисади кризис баткагын ерып, алга барабыз. Базарлар бик үк рәхимле түгел. Федераль хөкүмәтнең вице-премьеры Андрей Белоусов: «Көнчыгыш базарларда Россия ташкүмеренең бәясе хәзер тоннага 130–140 доллар. Бәя болай торганда, 2023 ел бюджетына экспорт пошлинасыннан керем керми», – дип белдерде. Ташкүмер акчасыннан башка да яшәп булыр иде булуын. Әмма Россия халыкара базарлардагы газга һәм нефтькә «бәяләр бәйрәме»ннән дә колак кага. Газга бәяләр гаҗәп югарылыкта торганда, краннарны үзебез яптык, «кара алтын» исә бик зур дисконт белән сатыла.

Мәскәүнең кыйммәтле рестораннарына йөрүчеләр саны соңгы ике атнада 30 процентка кимеде, диләр. Мобилизация шулай кайтаваз бирә. Кешеләр башкаладан китәләр. Фатир арендаларга теләүчеләр саны да кискен кимеде. Аның каравы Төркиядә фатирларга чират һәм аренда бәяләре күккә оча. Бу россиялеләр тырышлыгы белән шулай.

Төп ставканы төшерүгә карамастан, банклар ипотека процентларын югары күтәрә башлады. Беренчеләрдән булып Саклык банкы кредитны кыйммәтләндерде. Аңа ияреп ВТБ 9,9 процентлык ипотеканы 10,4 процент итте. Кредитоманнар исә күпләп банкротлыкка чыгалар. Өч кварталда 192,1 мең кеше бөлгәннәр исемлеген тулыландырган. Бу үткән елның шул чоры белән чагыштырганда 41,2 процентка күбрәк. Бурычын түли алмаучыларның 96,1 проценты банкротлыкны үзләре сайлый, 2,7 процент очракта кредиторлар бөлдерә, 1,2 процент кешегә салым органнары тарафыннан эш кузгалтыла икән.

Мобилизациягә бәйле рәвештә эш базарында эшче кулларга кытлык туып килә. 21 сентябрьдән соң бик күп кеше – халыкның актив һәм булдыклы катлавы, нигездә яшьләр, чит илләргә китте. Йөз меңләгән кеше кулына корал алырга мәҗбүр. Пенсия яшендәгеләрнең алар урынына басуы таләп ителә. Әмма бездә эшләдеңме – оттырасың: пенсия индексацияләнми. Соңгы җиде ел эчендә эшләгән пенсионерлар пенсияләренең өчтән берен югалтты, диләр. Болай да песи яларлык кына булган акчаның өчтән бере киселү авыр хәлгә куя. Дәүләт Думасы 14 октябрьгә кадәр яңа бюджет проектына тәкъдимнәр кабул итә. Бу уңайдан депутатлар арасында эшләүче пенсионерлар акчасын индексацияләүне кире кайтару идеясен күтәрүчеләр бар. Яңартылган Конституциядә дә индексация гарантиясе акка кара белән язылган. Владимир Путинның мәсьәләне хәл итәргә әмер бирүенә дә ике ел ярымнан артып китте. Әмма йөк һаман да үз урынында. Депутатларның бер төркеме бу хәлне икътисад өчен зыянлы дип чаң суга, әмма табышлары ишетелер дип әйтеп булмый. Бюджетка индексация өчен акча болай да аз салынган.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

БЕЗНЕҢЧӘ УКЫЙЛАР

tatarstan.ru

Үзбәкстанның Җизак шәһәрендә Казан (Идел буе) федераль университетының филиалы ачылды. Бу – республикадагы төп вузның чит илдәге беренче филиалы. Тантанада Президент Рөстәм Миңнеханов белән бергә Үзбәкстан Премьер-министрының ягулык-энергетика һәм химия тармакларын үстерү мәсьәләләре буенча урынбасары – энергетика министры Җурабәк Мирзамөхәммәдов катнашты.

Әлеге проект Үзбәкстан җитәкчелеге ярдәме белән тормышка ашырылды. Моның өчен бина бирелде, ремонт ясалды, җиһазлар сатып алу мәсьәләсе хәл ителә. Биредә машина төзелеше, геология, программа инженериясе, икътисад, мәгълүмат системалары һәм технологияләре, менеджмент, лингвистика, биомедицина фармациясе һәм журналистика кебек юнәлешләр буенча белгечләр әзерләнәчәк. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, филиалның нәкъ менә Үзбәкстанда ачылуы символик мәгънәгә ия.

– Безне күпьеллык нәтиҗәле хезмәттәшлек бәйли, бу элемтәләр соңгы елларда тагын да ныгый, – диде ул. – Әлеге филиалда яшьләрнең үз илләреннән китмичә, төрле юнәлешләр буенча сыйфатлы белем алу мөмкинлеге булачак.

Яңа филиалда уку 31 октябрьдә башланачак. Беренче курска – 300 студент, икенче курска 59 студент кабул иткәннәр. Сүз уңаеннан хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университетында 10 мең чит ил студенты белем ала, шуларның чиреге – Үзбәкстаннан.

Тантана алдыннан Рөстәм Миңнеханов Җизак өлкәсе хакиме Әргаш Салиев белән очрашты. Анда әлеге зур вакыйга турында сөйләштеләр. «Бу проектны гамәлгә ашыруда Үзбәкстан Республикасы җитәкчелегенә һәм шәхсән үзегезгә игътибар һәм ярдәм күрсәткәнегез өчен рәхмәт белдерәсем килә. Якын киләчәктә әлеге югары уку йортын тәмамлаучылар Үзбәкстанның ышанычлы таянычы булачагына һәм аның үсешенә үз өлешен кертәчәгенә ышанам», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Үз чиратында хаким Татарстан Президентына республика белән бу төбәк арасында эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруда зур өлеш керткәне өчен рәхмәт белдерде. «Сәүдә үсеше өчен машина төзелешендә, агросәнәгать комплексында мөмкинлекләр бар. Туризм өлкәсе аерым игътибарга лаек», – диде Әргаш Салиев. Президент сүзләренә караганда, бездә дә ике як өчен файдалы булырлык проектлар бар. Делегация вәкилләре катнашачак очрашуларда нәнә шул хакта сүз булачак.

Җизакта Татарстан вәкилләренә IT парк һәм күптелле мәктәпне дә күрсәттеләр. IT паркта яшь белгечләр белән әңгәмәдән соң Рөстәм Миңнеханов, ике ил белгечләре тәҗрибә уртаклаша алсын өчен, уртак килешүгә кул куярга кушты. Күптелле мәктәп 2021 елда ачылган. Бүген биредә 5 нче сыйныфтан башлап 168 бала белем ала. Үзбәк һәм инглиз телләрендә укыталар. Мәктәпне тәмамлаганнан соң бирелә торган сертификат халыкара югары уку йортларына керергә мөмкинлек бирә.

Җизактан соң Татарстан Президенты Ташкентка юл тотты. Биредә Рөстәм Миңнеханов төбәк башлыгы Зойир Мирзаев белән очрашты. Анда ул Мирзаевка «Чирчик» химия индустриясе технопаркы үсешенә керткән өлеше өчен рәхмәт әйтте. Билгеле булганча, әлеге проектны безнең «Химград» Үзбәкстандагы хезмәттәшләре белән бергәләп тормышка ашыра. Хәзер биредә 6 компания резидент булып урнашты. Тагын 6сы керергә җыена. Очрашуда «Чирчик» технопаркын үстерү турында сөйләштеләр. Татарстан Үзбәкстанга төрле тармаклар буенча белгечләр җибәрергә җыена. «Сезнең идарә тәҗрибәсе безнең өчен зур кыйммәткә ия. Илебез Президенты Россия төбәкләре белән мөнәсәбәтләрне үстерү бурычын куйды. Безгә Татарстан якын», – диде Зойир Мирзаев очрашуда.

Әти тәрбиясе

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Казанның 182 нче политехник лицеенда узган «Мөһим сөйләшү» дәресендә катнашты. Очрашуны Әтиләр көненә багышлап оештырдылар. Билгеле булганча, әлеге бәйрәмне 16 октябрьдә билгеләп үтәләр.

Дәрес тантаналы рәвештә дәүләт әләмнәрен күтәрү, гимн башкарудан башланды. Фәрит Мөхәммәтшин «Мөһим сөйләшү» дәресләре кысасында ватанпәрвәрлек тәрбияләүне бүгенге шартларда аеруча әһәмиятле булуын ассызыклады.

– Ватанпәрвәрлек, Ватанга мәхәббәт, илебез һәм республикабыз өчен горурлык хисләре нәкъ менә мәктәпләрдә тәрбияләнә. Патриотлар гаиләдә туа, мәктәптә ныгытыла. Бу – Ватанга, әти-әнигә, педагогларга карата мәхәббәт таләп итә торган тәрбия, – диде ул.

Әтиләр көне уңаеннан узган «Мөһим сөйләшү»дә Фәрит Мөхәммәтшин фронтовик әтисе турында истәлекләре белән уртаклашты.

– Кеше тормышында беренче тәрбияче, укытучы – әтиәнисе. Һәркем алар турында озак сөйли ала. Мин дә шулай. Әти Бөек Ватан сугышында катнашкан, без – сугыштан соң туган балалар. Гаҗәеп кеше иде ул. Аннан калган истәлекләр дәфтәрен әле дә саклыйм. Безгә бирелгән мәңгелек кыйммәтләр, яхшы тәрбия өчен әти-әниемә бик рәхмәтлемен. Ата тәрбиясе алган, Ватанын яраткан һәм аңа хезмәт иткән яшьләребез – киләчәгебезнең нигезе, – диде ул.

Дәүләт Советы Рәисе үз чыгышында укытучыларга да мөрәҗәгать итте. Белем һәм тәрбия бирү эшендә аларның роле зур булуын искәртте.

– Беренче тәрбия дәресләре гаиләдә әти һәм әни тарафыннан бирелә. Гаилә биреп җиткереп бетерә алмаган урыннарны мәктәпкә тулыландырырга, хәтта төзәтергә дә туры килә. Белем бирү, тәрбияләү һәм республикабызга, илебезгә карата ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү бурычы бүген мәктәпләр өчен бик актуаль. Алга таба да бу юнәлештә эшне дәвам итәчәкбез, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәрес барышында укучылар үзләренең сорауларын да җиткерделәр. Казанда әтиләргә багышланган һәйкәл булырмы, дип кызыксындылар. Сорауга Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин җавап җирде:

– Республикада матур итеп Әниләр көнен, хәзер инде Әтиләр көнен дә уздырабыз. Миңа калса, әти-әнигә хөрмәтебезне күрсәтә торган һәйкәл һәрберебезнең йортында булырга тиеш. Чөнки өй – әти-әнигә кадер-хөрмәт белән карый торган урын. Бәлки, күпмедер вакыттан соң ул шәһәрдә дә барлыкка килер.

Дәрес тәмамлангач, Фәрит Мөхәммәтшин мәктәпнең китапханә фондына үзе язган «Әти турында истәлек» һәм дүрт томлы «Татарстанның яңа тарихы» китапларын тапшырды.

Ләйсән САФИНА

tatarstan.ru

«ТӘГӘРМӘЧЛЕ» УКЫТУЧЫЛАР

СӘЛИМОВЛАР ГАИЛӘСЕ КӨН САЕН МАМАДЫШТАН АЛАБУГАГА БАРЫП УКЫТА

Алабуга

Мамадыш районында яшәүче Сәлимовларны «тәгәрмәчле» укытучылар дип йөртәләр. Алар Алабуга районының Олы Шүрнәк мәктәбенә барып белем бирә. «Юл газабына түзәргә була, тик мәктәпләрдәге кәгазь боткасына, әти-әниләрнең тискәре мөнәсәбәтенә һәр укытучы чыдый алмый», – ди Илгиз белән Рәмзия. «Мобиль укытучы» грантын откан гаилә белән юл мәшәкатьләре, белем бирү проблемалары турында сөйләштек.

Сәлимовлар Алабуга районында ят кешеләр түгел, беренче тапкыр анда 2019 елда ук килгән булганнар. Тик бер елдан соң тормыш иптәше декрет ялына киткәч, Илгиз Мамадышка укытырга кайткан. Хәзер кабат Олы Шүрнәктә эшли башлаганнар. Илгиз – ОБЖ, физик культура, Рәмзия исә инглиз теле дәресләрен укыта.

– Без эшли башлаганда «Мобиль укытучы» проекты юк иде. Шуңа күрә грантка кызыктык дип әйтә алмыйбыз. Йөрергә ерак дип, башта мәктәп директоры йорт тәкъдим иткән иде. Яшелчәчелек белән шөгыльләнүче фермер өйләр салдырган, тик күбесе буш тора. Безнең нигәдер чит җирдә төпләнеп каласы килмәде. Мамадышта яшибез, ике кыз тәрбиялибез. Узган ел мәктәп директоры, әлеге программада катнашып карамыйсызмы, дип шалтыратты, әмма грант эләкмәде. Быел без җиңдек. Ачкычын тапшырдылар инде, машинасын бу атнада бирергә җыеналар. Әлегә үзебезнекендә йөреп торабыз, – ди Илгиз Хәлимович.

Илгизгә – 44, Рәмзиягә – 38 яшь. Әлеге гаиләнең көнгә ике сәгате юлда үтә. Бер якка гына 45 чакрым барасы. Шуңа күрә иртүк сәгать 5тә аяк өстендә алар. Бу тәртипкә күптән ияләшкәннәр инде. «Кышын бозлавыкта йөрү генә уңайсыз», – диләр. Бу урында Илгиз: «Йөреп эшләргә иренмим. Моңа кадәр өч ел Мамадыш районының

elabuga-rt.ru

Катмыш авылы мәктәбенә барып укыттым. 50 чакрым ераклыкта урнашкан иде ул», – ди.

Олы Шүрнәк урта мәктәп булса да, быел анда 10–11 нче сыйныфта укучылар юк. Төрле авыллардан 30дан артык бала укый монда. Арада мари, татар, керәшеннәр дә бар. Татар теле дәресләре укытыла, әмма аралашу, укыту күбрәк рус телендә башкарыла.

– Бала кайда да бала инде ул. Кайберләре ерактан килеп йөрүебезгә гаҗәпләнсә, кайберләре бу хакта бөтенләй белми, – ди Илгиз әфәнде. – Элек укытырга җайлырак иде. Кәгазь эшен киметтек, дисәләр дә, үзгәрешне сизмибез. Электрон почтаны көн саен карап торам, тегеяки бу бәйгедә катнашырга яки чаралар үткәрергә дигән хатлар килеп кенә тора. Нәрсәдер эшләп җибәрергә кирәк. Укыту бүген – икенче планда. Кәгазьдә тәртиптә булса, шул әйбәт санала инде. Бу бит дәреснең сыйфатына йогынты ясый.

Илгиз Сәлимов мәктәптә үзен алдан пенсиягә чыгу мөмкинлеге, ягъни «выслуга лет» тотуын яшерми. Элек укытучыга моның өчен 25 ел җитсә, хәзер 30 ел кирәк. Тормышны яңадан сайлыйсы булса, бервакытта да укытучылыкка бармас идем, ди Илгиз. Үз балаларын да, берүк укытучы булма, дип тәрбиялиләр икән.

– Мәктәптә бала саны кимеде. Укытучыга хөрмәт юк анда, – ди ул. – Элек укытучы мәктәптән баланы сүгеп кайтарса, әти-әниләр: «Укытучың хаклы, аңа каршы әйтмә», – дип ачулана иде. Хәзер алай түгел. Әти-әниләр кем гаепле икәнен тикшереп тормый. Мәктәпкә килә дә, ник минем балага ялгыш сүз әйттең, ник кырын карадың, ди.

Акча турында да сөйләштек. Илгиз Сәлимов әйтүенчә, 2013 елда укытучыларның хезмәт хакы сизелерлек арткан. Ул вакытта ике еллык эш хакына «иномарка» сатып алып булган, бүген бу акчага чит ил машинасы тими. Акчага чыгар юл табылып кына тора. Мәктәпләрдә дә тегендә-монда акча җыеп торалар. «Мин 20 елга якын мәктәптә эшлим, безгә бервакытта да принтер кәгазе биргәннәре юк. Бер оешмада да кеше аны үз акчасына сатып алмый. Принтер да – үз хезмәт хакыбыздан. Берсе эштән чыкты, хәзер икенчесе дә сафтан чыгып килә», – ди педагог.

Сүзгә Рәмзия Сәлимова да кушылды. Ул – Кукмара районының Түбән Өскебаш авылы кызы. Алабуга педагогика институтын тәмамлагач, хезмәт юлын Мамадыш районында башлап җибәргән. Ун ел эшләгәч, ире Илгиз белән гаилә корып җибәргән. Укытучы һөнәрен бик яратып сайлаган булган, тик…

– Йөреп эшләү рәхәт түгел. Федераль юлдан барасы бит. Бензинга ай саен 8–9 мең сум китә, – ди ул юл мәшәкатьләре турында. – Шәһәрдә сыйныфларда укучылар күп, эш авыр булса да, мәктәпкә атлыгып килә идем. Хәзер югыйсә бала саны да аз…. Әмма семинар, вебинар, курслар дип, тегендә-монда йолкып торалар. Рәхәтләнеп дәрес укытырга тынгылык юк. Өйгә кайткач, үз балаларыңа да игътибар кирәк бит. Алар белән урамда йөрисе, кино, мультфильмын да карыйсы килә. Шул вакытта «Ватсап»тан, фәлән хисапны фәлән сәгатькә кадәр тапшырыгыз, дигән хәбәр килеп төшә. Кәгазь эшен бетердек, диләр, әмма алар бит барыбер компьютерда калды. Укытучының хәзерге халәте авыр. Юк-бар бәйгеләр бетерелсен, мөгаллимнәрнең укучы белән эшләргә вакыты калсын иде. Чын күңелдән эшләү бетеп бара. Бөтен мәктәптә шундый хәл хәзер. Башка укытучылардан да ишетеп торабыз бит. Элек эшкә яратып йөри идем, хәзер кемне генә тартып тора икән ул?! Мәктәпкә килүгә, бу хисап бирелмәгән, бу эш программасы язылмаган, миннән бүген аны сораячаклар инде, дип борчыла башлыйсың. Бу бәйгедә катнашмаган, инде аның вакыты җиткән… Укучыларны башта әзерләргә кирәк бит әле.

Сәрия МИФТАХОВА

Белешмә

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, «Мобиль укытучы» проекты Әгерҗе, Алабуга, Әлки, Апас, Әтнә, Баулы, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Кайбыч, Лениногорск һәм башка районнарда тормышка ашырыла.

Мин кулыма китап алдым

ӘДӘБИ БӘЙГЕЛӘРНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ

«Казан утлары» журналы берничә ел элек башлап җибәргән әдәби әсәрләр бәйгесе үзе бер вакыйга булып тора. Ул яңалыгы белән дә, нәтиҗәлелеге белән дә әһәмиятле.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Беренчедән, ул киң колачлылыгы белән ота: татар дөньясының төрле төбәкләрендә яшәгән мәктәп балаларыннан алып профессиональ язучыларга кадәр катнаша һәм җиңә ала. Бу бәйгедә җиңү яулаган балаларның шатлыгын күз алдына китерү кыен түгелдер: «Казан утлары» – татарның иң зур, иң абруйлы журналы, анда беренчелекне алу теләсә кайсы мәктәп укучысының кулыннан килмидер. Бу – үзе үк яшь иҗатчыларга канат куя торган күренеш. Әле аны менә болайрак та итеп күз алдына китерергә мөмкин. Авылда хәбәр тиз тарала бит инде. Менә сезнең авылдан бер бала, бәйгедә җиңеп, диплом һәм ярыйсы гына суммада акча алып кайтты ди. Шатлык! Авыл халкы, тыштан күкрәк сугып йөрмәсә дә, шатлана, горурлана бит инде үзенең шундый балалары белән. Хәтта гомере буена җиргә туңкаеп гомер иткән, әдәби журналның, хәтта әдәбиятның нәрсә икәнен элек белмәгән, хәзер оныткан кешеләр дә, тураеп басып, башын кашып куя: «Карале, язу язып та акча эшләп була икән бит… Шундый-шундый журнал белән… Минем дә малай бар бит, тырышып караса, берәр рәт чыкмас микән?» Икенче төрле әйткәндә, бу – балаларны гына түгел, ә аларның ата-аналарын, таныш-белешләрен дә әдәбиятка игътибар бирергә мәҗбүр итүче күренеш. Ә кызыксыну, ярату игътибар итүдән башлана.

Икенчедән, темалар төрлелеге әдәбиятыбызның офыкларын киңәйтә. Нефтьчеләр тормышына, Бөек Ватан сугышына, медицина өлкәсенә кагылганнары булды. Мин бу бәйгегә повестьлар белән катнашып, эреле-ваклы җиңүләр яулаштырдым. «Кайту» дигәне беренче урынга да чыкты әле. Хәзер төгәл генә әйтә дә алмыйм инде, әгәр шундый бәйгеләр үткәрелмәсә, мин бу темаларга алынып идем микән? Белмим. Күңелдә булган нәрсә барыбер бер бәреп чыгар иде, бәлки. Ә икенче яклап карасаң, безнең күңел хатын-кыз сумочкасы шикеллерәк бит инде, ни генә юк анда?! Ихтыяҗ чыкмаса, күп нәрсәләрне эзләп тә тормыйсың, алар шунда гомер буе ята бирә, кайберләрен хәтта кирәк чагында да табып булмый. Иҗади бәйгеләр язучыда хәтта үзе дә белмәгән потенциалны ачарга ярдәм итә.

Өченчедән… «Казан утлары» журналы уздырган бу бәйгенең даими кабатланып торуы мөһим. Бу үзе үк авторны иҗатка көйли. «Монысында катнаша (җиңә) алмадым, киләсе елда мотлак катнашачакмын!» – дип чәмләнергә мәҗбүр итә. Укучыларда, әдәбият сөючеләрдә дә кызыксыну уяна. «Узган ел фәлән-фәлән язучы җиңгән иде, монысында кем алга чыгар икән?» – дип көтә алар. Һәм үзләре өчен генә, гаделме-юкмы икәнен билгеләү максатыннан, катнашучы авторларның әсәрләрен укып чыгу теләге уяна. Әдәбиятка игътибарны арттыру өчен менә шундый бәйгеләрнең даими уздырылуы мөһим.

Язучылар берлеге дә әледән-әле шундый конкурслар үткәреп тора. Берничә ел рәттән авыл темасына багышланган әсәрләр ярышы барды. Кайберләре бик артык рекламаланмыйча гына үткәрелгәч, йомгаклары да шау-шусыз гына узгач, бу ниндидер бер даирә өчен генә микән әллә, дигәнрәк сорау белән мыек астыннан елмаерга да мәҗбүр итте. Алай түгелдер, оештыручыларның тәҗрибәсезлегеннән генә булгандыр. Соңрак анда шактый җитди авторлар да җиңеп чыкты, бик матур әсәрләр яздылар. Әйбәт башлангыч иде ул. Чөнки бүген авыл кешесе әдәбияттан бераз читтәрәк кала. Почта хезмәтен оптимальләштергәч, газета-журналлар да атнасына бер, күп дигәндә ике тапкыр таратыла. Почта аша китап кайтартырга теләсәң, ике бәясенә төшә. Ә акча ул авылда да акча, аз булгач, санап тотарга мәҗбүр буласың. Шул рәвешле, авыл кешесе китаптан бизә бара. Әгәр әдәбият авыл кешесе белән кызыксынса, авыл кешесе дә әдәбият белән кызыксынып иде кебек. Ни өчендер миңа шулай тоела. Әмма соңгы вакытта бу бәйге дә тукталып калды. Ул чактагы авыл хуҗалыгы министрының башка өлкәгә күчүенә бәйле булды, күрәсең.

Аның каравы Татарстан Язучылар берлеге узган елда «Татар халкының милли тәңгәллеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысасында Роберт Миңнуллин исемендәге конкурс уздырды. Төрле жанрларны (шигырь, проза (хикәя, повесть), комикслар һәм скетчлар) колачлаган бу конкурс балалар һәм үсмерләр әдәбиятын баету җәһәтеннән дә, яңа авторлар ачу ягыннан да бик матур чара булды. Аның бурычлары да шул иде. Ә инде конкурс бурычларының «Татар телен балалар һәм үсмерләр арасында популярлаштыру» дигәне бер бәйге эчендә генә хәл ителә торган мәсьәлә түгел. Үсмерләр әдәбиятына игътибар юнәлтү – үзе үк зур нәрсә, чөнки ул бездә ничектер сүлпәнрәк бара: балалар әдәбияты бар, зурларныкы бар, ә үсмерләр үгисетелә – кечкенәдән татарча укып үскән бала үсмерлек чорына кергәч, үз телендә үз яшенә туры килерлек әсәр таба алмый, чылбыр өзелеп кала. Шуңа күрә үсмерләргә бүген аеруча игътибар кирәк. Язучылар берлеге бу эшне бик матур башлап җибәрде, дәвамы тагы да уңышлырак булыр дигән өмет бар.

Татарстан Президенты карамагындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү комиссиясе һәм Татарстан Язучылар берлеге оештырган ябык әдәби конкурс узган елның олы бер вакыйгасы булды. Ул әдәбиятның барлык жанрларын да диярлек колачлады, матбугатта да әйбәт яктыртылды, татарларның игътибарын яулап, әдәбият белән кызыксынуларын уятып җибәрерлек зур бәйге булды. Җиңүчеләрне билгеләүнең ябык булуы да, берничә этапта уздырылуы да, һәр этапның ачыктан-ачык яктыртылып баруы да кызыксыну көчен арттырып торды, киң катлауларны колачлауга китерде. Җиңүчеләр өчен игълан ителгән сумманың ярыйсы ук зур булуы да үз эшен эшләгәндер. Әдәбият белән кызыксыну – бер нәрсә, ә акчага төрелгән әдәбият белән – күпкә көчлерәк. Шуңадырмы, социаль челтәрләрдә дә ул киң яңгыраш алды, фикер алыштылар, бәхәсләштеләр, кем җиңәр дип гөманладылар. Бәхәсләргә хәтта чит төбәкләрдә яшәп, бу чара турында ишетми калганнар да кушылып китте. Бүләк күләме дә, язучылар да, аларның иҗаты да читтә калмады. Җиңүчеләр билгеле булгач, шатланучылар да, канәгатьсезлек белдерүчеләр дә табылды һәм хис-тойгылар уены яңа бер дулкын булып күтәрелде. Җиңүчеләрнең әсәрләрен таптыручылар, эзләп йөрүчеләр күбәйде. Бәйге турындагы хәбәрләр, кызыксыну татарлар яшәгән иң ерак төбәкләргә дә, төпкел авылларга да барып җитте. Кешеләрнең игътибарын әдәбиятка юнәлтүнең уңышлы бер үрнәге бит инде бу.

Әдәби бәйгеләрнең әһәмияте әйтеп бетергесез. Бу – әдәби процессны дәррәү кузгатып җибәрергә һәм тиешле юнәлештә хәрәкәтләнергә мәҗбүр итүче иң зур көчләрнең берсе. Әйтик, үсмерләр әдәбиятына кагылышлы бәйгеләр оештырыла һәм берничә ел дәвам итә икән, бу өлкәдә безнең кытлык бетәчәк. Әдәбиятка нинди темалар, нинди жанрлар җитми – барысын да диярлек бәйгеләр ярдәмендә хәл итәргә була. Ул – авторларны язарга, укучыларны укырга әйди алырлык тылсымлы көч. Һәм аны кулланырга кирәк. Әлбәттә, күпмедер чыгымнар сорый инде, тик шунсыз беркая да барып булмый, хәтта трамвайга утырып, бер тукталыш бару өчен дә күпмедер түләргә туры килә бит.

Әдәбиятны баетуы, популярлаштыруы, язучыларны эшләргә мәҗбүр итүе, аларның матди хәлен матурлап җибәрүе өстенә, тагын бер мөһим ягы бар әле аның. Татар теле ярдәмендә күп кенә акча алу мөмкинлеген күрү хәтта милли тойгылардан читтәрәк торган катлау алдында да телнең һәм милләтнең абруен күтәреп җибәрә. Миллилектән читкә тайпылу ул бит – үз халкыңны яратмау түгел, ә аннан оялу, башкалар алдында горурлана алырлык мөмкинлек тапмау нәтиҗәсе.

Бәлки, бу әдәбиятка гына кагылмый торгандыр инде, ярышып эшләнгән һәрбер эш нәтиҗәлерәк була бит…

P.S. Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә икенче мәртәбә үткәрелә торган әдәби бәйгенең акчалата призы күләме – 3 миллион 895 мең сум. Быел бәйгенең номинацияләре – «Роман», «Повесть», «Хикәя», «Поэма яки шигырьләр шәлкеме», «Повесть (үсмерләр әдәбияты)», «Хикәя (үсмерләр әдәбияты)», «Поэма яки шигырьләр шәлкеме (балалар һәм үсмерләр әдәбияты)», «Хикәя (балалар әдәбияты)», «Кыска драма әсәрләре, скетчлар (балалар әдәбияты)», «Әдәби тәнкыйть мәкаләсе, Рецензия». Романнар – 2023 елның 1 декабренә, башка номинацияләрдәге әсәрләр 2023 елның 1 сентябренә кадәр кабул ителә.

Марат КӘБИРОВ

Җирне ничек бүләргә?

Сорау – җавап

Биләмәң бар икән, аны дөрес итеп рәсмиләштерергә дә кирәк. Законнар каттыйрак шул хәзер, элеккеге кебек кул селтәп кенә йөрсәң, буш кул белән калуың да бар. Ә кешеләрнең күбесе моңа һаман ияләшеп җитә алмый. Шуңа күрә аңлашылмаучанлыклар да күп. Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе җитәкчесе урынбасары Нияз ГАЛИӘКБӘРОВтан аеруча еш очрый торган шундый сорауларның кайберләренә җавап бирүен үтендек.

? Җир участогы милек буларак күчерелгән очракта, аның мәйданын һәм чикләрен билгеләү өчен эшне нидән башлыйсы?

– Бу максаттан җир участогына ызанлаштыру планын әзерләү өчен кадастр инженерына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Белгечләр биләмә чикләрен билгеләп кенә калмыйча, бу документка җир участогының кайда урнашканын күрсәткән аңлатмаларны да кертәчәкләр.

? Шәхси торак төзү өчен 800 кв. м мәйданлы җир участогына рөхсәт бар. Белгәнебезчә, төзү һәм җирдән файдалану кагыйдәләре буенча җир участогының минималь күләме 600 кв. м дип күрсәтелгән. Бу очракта участокны ике өлешкә бүлеп буламы?

– Җир законы буенча, җир участоклары максималь яки минималь размер чикләрендә булырга тиеш. Минималь чиге – 600 кв. м. Бу очракта 800 кв. м мәйданны икегә бүлсәгез, берсе кагыйдәләргә туры килгән очракта да, икенчесе законда күрсәтелгән күләмнән кимрәк булып чыга. Димәк, бу биләмәне берничек тә бүлеп булмый.

? Шәхси биләмәне дәүләт милке булып саналган җирләрне сатып алу юлы белән зурайтырга мөмкинме? Бу эшне нидән башларга һәм нинди документлар әзерләргә?

– Шәхси милек булып саналса да, дәүләт яки муниципаль милек булган очракта да, җир участокларын киңәйтү ике якның да килешүе буенча башкарыла. Мондый килешү төзегәнче, иң беренче чиратта белешмәләр җыярга кирәк: участокларның чикләре билгеләнгәнме яки юкмы, кадастр исәбендә торамы яки юкмы икәнен ачыклау таләп ителә. Әгәр берниндидисе каршылыклар булмаса, җирнең сайлап алынган өлешенә ызанлаштыру планын төзергә кирәк. Бу эшне, алда әйткәнебезчә, кадастр инженерлары башкара. Моның өчен ике якка да (документны ике якның берсе генә рәсмиләштерергә мөмкин), документлар җыеп, күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

? Ызанлаштыру барышында күп вакытта җир участогының бер өлеше күршеләрдә «утыруы» ачыклана. Бу очракта нишләргә?

– Мөгаен, бу очракта күршеләрнең участогы да ызанлаштыру планыннан башка гына рәсмиләштерелгән булгандыр. Башта чикләрне дөрес билгеләү мәсьәләсен күтәреп, күршеләрегез белән сөйләшеп карагыз. Әгәр берни дә барып чыкмый икән, ызанлаштыру планы нигезендә чикләрне билгеләү өчен, судка мөрәҗәгать итүдән башка юл юк.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

КОТЛЫЙБЫЗ!

Фән үсешенә керткән өлеше һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен физика-математика фәннәре докторы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Мәгълүмат технологияләре һәм интеллектуаль системалар институты профессоры **Елизаров** Александр Михайловичка Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Медицина красоты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Жабоева** Светлана Леоновнага Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе начальнигы **Тимерҗанов** Марат Исмәгыйль улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре, күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «БӨРЕЛЕ» ябык акционерлык җәмгыяте генераль директорының сәүдә һәм көнкүреш хезмәте буенча урынбасары (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Баһавиева** Раилә Шәрипҗан кызы, «Чынлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш икътисадчысы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Бухаров** Тәлгать Солтан улы, «Игенче» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш агрономы (Татарстан Республикасының Арча районы) **Вахитов** Марат Мирзаян улы, «Таң» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы баш агрономы (Татарстан Республикасының Әтнә районы) **Халиков** Шакирҗан Мөхәммәтҗан улы; күпьеллык намуслы хезмәтләре, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Гәрәев** Фәрит Каюм улы, Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Суворов** Андрей Николаевич; халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Зиатдинов** Айрат Илгизәр улы, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш миендә кан әйләнеше кискен бозылган авырулар өчен неврология бүлекчәсе мөдире – табиб-неврологы **Яркәев** Әхтәм Галләм улы; күпьеллык намуслы хезмәтләре һәм һөнәри эшчәнлеклектәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире урынбасары **Попова** Елена Владимировна, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының дәүләт сатып алулары һәм административ-хуҗалык эшчәнлеге бүлеге башлыгы **Фәтхетдинов** Әнәс Габдулхак улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен хезмәт ветераны **Заһидуллин** Рәшид Нәҗиб улы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары **Старостин** Александр Владимирович, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы **Хәсәнов** Булат Фаяз улы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы **Хөснетдинов** Фиргать Әхсән улы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

БИЛГЕСЕЗЛӘР БЕР ТАБЫЛА...

Кечкенәдән әтисен күрәсе килеп яшәгән Гөлфирә ханымга әлеге хыялын Зәй районының Федоровка авылында тормышка ашырырга насыйп булды. Язын авыл зиратын чистартканда, Бөек Ватан сугышы ветераны Галимҗан Зәки улы Әхмәтвәлиевнең кабере табылды. Федоровкалылар, киңәш-табыш итешеп, ветеранның каберенә кую өчен һәйкәл ясатты.

Әлеге игелекле эш башында торган Валентин Атласов ветеранның гаиләсен, туганнарын эзләү хәстәренә керешә. Бу турыда мәгълүмат эзләшүдә булышуны сорап, «Зәй офыклары» район газетасына да мөрәҗәгать белән чыкты.

– Гомеренең соңгы көннәрен авылыбызда үткәргән Галимҗан Әхмәтвәлиев турында мәгълүматлы булу өчен, эзләнү эшләре алып бардык. Ул – «Мәскәү оборонасы өчен», «Кенигсбергны алган өчен», «Германияне җиңгән өчен» медальләренә ия ветеран булып чыга. Эзләнсәң, эзгә төшелә икән, – ди Валентин Атласов.

Шактый мәгълүмат табыла, тик эш башында ветеранның гаиләсе генә табылмый. Галимҗан Әхмәтвәлиевнең кызы барлыгы авыл халкы, хәрби комиссариат катнашында, имам хәер-догасы белән таш урнаштырылгач кына ачыклана. Һәм бу көннәрдә Әлмәт районының Тайсуган авылында яшәүче Гөлфирә Мәрдамшина, балалары һәм оныклары белән Федоровка авылына килеп, әтисенең каберен күрде.

– Әнием Гаҗилә бик сабыр, әтием, киресенчә, кызу канлы кеше иде. Сугыштан шундый холыксыз булып кайткандыр инде ул. Миңа – алты, абыема сигез яшь булганда, әнием, әтиемнән аерылып, Үзбәкстан якларына апасы янына яшәргә чыгып китә. Үзбәкстаннан бирегә кайткач, әтием, минем белән очрашырга теләк белдереп, хат юллаган иде. Балалар кечкенә, тормыш иптәшем эшли дә, укый да иде, һич форсат булмады, абыем да бакыйлыкка күчте, – ди Гөлфирә ханым.

Әтисенең Зәй якларында яшәве турында ишетеп белә ул, тик очрашу теләген тормыш мәшәкате баса.

Галимҗан Әхмәтвәлиев – тумышы белән Әлмәт районы Нәдер авылыннан. Армия хезмәтенә 1940 елда Юдино хәрби комиссариаты аша алына, 1948 елда исә демобилизацияләнә. Язмыш аны Зәй районының Федоровка авылы һәм Мария Головина белән бәйли. Федоровка аксакаллары аның колхозда эшләгәнен, гомеренең соңгы көннәрен яхшы хәтерли.

Сүз уңаеннан, районда иң кечкенә авыллардан саналган Федоровка авылы халкы сугыш ветераннарына хөрмәтле. Алар уртак тырышлык белән фронтовикларга һәм тыл хезмәтчәннәренә багышланган һәйкәл төзеделәр. Әлеге Хәтер мемориалына якын-тирәдә тиңнәр юк. Гөлфирә ханым әлеге авыл халкының эчкерсезлегенә, игелекле эшләр белән януларына соклануын яшерми.

– Әтием кабренә ел да киләчәкбез. Православие динендә булган федоровкалыларның әтием каберенә игътибарлы булулары, таш куюлары сокландыра, бу эшне оештыручы Валентин Атласовка чиксез рәхмәтлебез, – ди ул.

Галимҗан ага оныклары каһарман бабалары белән горурланачак, кабере зиярәт кылынып, аның рухына дога барып торачак.

Рәзимә КАШАПОВА

Язмыш

«Әни безнең көрәшкәнне карамады»

Балтач

Балтач районының Яңгул авылы республикада көрәшчеләр төбәге буларак билгеле. Биш бертуган Әхмәдиевләр, өч бертуган Рәфыйковлар (хәзер дәвамчылары да берничә), Ранил Габдрахманов... Гади бер авыл укытучысы Газиз Газыймовның заманында үз эшенә фанатларча бирелүе сәбәпче моңа. Бик күп ярышларда җиңүче, РСФСРның спорт мастеры Илдар Рәфыйковтан ничек көрәшә башлавы турында сорашам.

– Әти көрәшче түгел иде безнең. Мәктәптә мәрхүм Газиз абый Газыймов көрәш түгәрәге оештыруга, Габделфәрт абый йөри башлады, аннан күреп, энекәш Илһам белән без дә кызыксынып киттек, – ди Илдар. – Башта ул бер кызыксыну кебек кенә иде. Өйдәгеләр дә аңа әллә ни игътибар бирмәде. Тугызынчы сыйныфны тәмамлаган елны күрше Борнак авылы Сабан туена көрәшкә кердем һәм батыр калдым. Өйдәгеләр көрәшкәнне белми дә калды. Миннән алда батырга биргән шул тәкәне алып кайткан кешеләргә әби: «Бу безнең тәкә түгел бит, ялгыш кертәсез», – дип каршы да килгән әле... Шуннан китте инде...

– Өч улының тоташ дип әйтерлек бәйгеләргә йөрүенә, көрәшүенә әниегез ничек түзде, ничекләр рөхсәт бирде икән?

– Әни курка иде инде. Ул беркайчан безнең көрәшкәнне карамады. Ярышларга озатканда да җиңеп кайтыгыз дип түгел, имгәнә күрмәгез дип теләп кала иде. Әмма җиңүләребезгә өйдәгеләр барысы да шатлана иде... Әле оныклары җиңә башлагач та, бик сөенделәр... Тик күңелдә бер үкенеч калды. 2020 елда әти белән әнине, 63 ел бергә гомер итүчеләр дип зурлап, район күләмендә бүләкләделәр... Икесенең дә юбилейларына ихлас теләкләребезне әйтеп, район газетасына котлаулар да бирдек, гомер буе кадер-хөрмәт тә күрсәттек кебек. Әмма әти исән вакытта алар турында газетага яздырта алмадык. Юкса хыялда бу әйбер күптән бар иде бит... – дип, Илдар сүзне бөтенләй башка юнәлешкә алып кереп китте. Үз гомерендә күп алышларда җиңгән, батыр калып макталган, «РСФСРның спорт мастеры» дигән дәрәҗәле исемгә лаек булган пәһлеван йөрәген дә нечкәртә ала торган хис шул әти-әнигә булган мәхәббәт. Өстәвенә үткән ел ковид дигән замана зәхмәте аларны да читләтеп үтмәгән...

– Әти-әни, төп йортта яшәүче энекәш өчесе берьюлы хастаханәдә ятты, әти, кызганыч, күтәрә алмады, вафат булды, әни белән энекәш озатырга да кайта алмадылар... Бу үкенеч әнә шул көннән бирле җанны кимерә инде, – ди Илдар. – Дөрес, заманында әни дә, әти дә күп макталды, алар үз эшләрен җиренә җиткереп, булдырып эшли торган кешеләр иде. Әтиебез Габделбәр – Яңгул егете, әниебез Нурания Бөрбаш Сәрдегәнендә туып-үскән. Анда безнең туганнар яши иде, шунда кунакка барган җирдән танышалар, гашыйк булалар һәм яшьли гаилә корып, 63 ел буе алар бик матур гомер кичерделәр. Әтиебез районда танылган комбайнчы иде, озак еллар эшләде һәм күп мәртәбәләр җиңү яулады, ул заман өчен иң зур бүләк – мотоцикллар белән дә бүләкләнде. Әниебез исә алдынгы сыер савучы булды, фермаларда эшнең иң авыр, күп елларында эшләсә дә, без аннан беркайчан арыдым дигән сүзне ишетмәдек. Ә бит җәйдән көзгә кадәр әти басуда, өйдәге бөтен авыр эш аңа калган... Алар шундый тырыш булганга, без үскәндә бер авырлык та күрмәдек, бар яктан житеш, мул тормышта яшәдек. Укыттылар да, акыллы киңәшләрен дә бирделәр, һәрчак аңладылар һәм кирәк чакта ярдәм кулы да суздылар. Без аларга барысы өчен дә бик рәхмәтле. Без көрәшеп йөргән елларда әбиебез дә исән иде әле, әни белән алар 33 ел әниле-кызлы кебек яшәделәр...

Бу гаиләдә биш бала үсә – ике кыз, өч малай. Балаларның үскән берсе әтиләрендә ярдәмче булып эшли. Кызлар да, малайлар да үтә бу этапны. Малайлар әле аннары үзләре дә комбайнга утыра. Эшләп үскән, хезмәттә чыныккан егетләр бер-бер артлы көрәшкә тартыла... Һәм бер-бер артлы зур җиңүләр яулап, әти-әниләрен сөендерә... Тик тормыш дигәнең җиңүләрдән, шатлыклардан гына тормый шул. Үткән гомере эчендә әни кешегә дә югалтуларның, хәсрәт-кайгыларның төрлесен күрергә туры килгән. Габделфәртен, Нуриясен, үзе белән бергә яшәүче, ике сабыен калдырып, кан авыруыннан яшьли вафат булган киленен соңгы юлга озатырга, оныкларына әни җылысын да бирергә туры килә аңа. Моңа кадәр тигез яшәүләренә шөкер итсә, аның бик сирәкләргә туры килгән бәхет икәнен аңласа да, картын югалту хәсрәтен әле дә булса бик авыр кичерә. Ярый әле, андый авыр чакларында иңен терәргә балалары, юату сүзләре әйтергә онык-оныкчыклары бар. Ни дисәң дә, тармаклы агач җиргә егылмый шул, ботакларына таянып кала. Әнә шул «ботак»лары Нурания апага әле гомер көзләрендә күп еллар ныклы таяныч булсын, бәхетле картлыкларның түмен дә, ямен дә тоеп яшәргә язсын иде.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ (843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

АЛИЯ ФӘЙЗРАХМАНОВА:

«МИН БАЛАЛАРГА ЫШАНАМ»

Быел февральдә Казанда татар балалары өчен уникаль студия эшли башлады. Аның үзенчәлеге нидә? Башка студияләрдән нәрсәсе белән аерылып тора? «Апуш» балалар татар театр студиясе җитәкчесе Алия ФӘЙЗРАХМАНОВА белән сәләтле балалар һәм аларга бирелгән мөмкинлекләр турында сөйләштек.

:: Алия, әлеге студиянең максаты нинди?

– Театр студиясе булдыруның төп максаты – балаларда, яшьләрдә татар телен популярлаштыру, аңа мәхәббәт уяту һәм татар сәнгатенә, иҗатына сукмак салу. Моннан тыш, аларның эчке иҗади сәләтләрен ачу, киләчәктә театр юлын сайларга уйлаган балаларга юнәлеш, һөнәри белем бирү. Иң элек, Татарстанда балалар театры булырга тиеш, дигән зур максатыбыз бар иде, чөнки безнең балаларыбыз аңа лаек. Санкт-Петербургта яшь актерлар театры бар. Анда балалар барысын да үзләре эшли һәм спектакльләрен укучыларга тәкъдим итәләр. Аларны тамаша кылган балалар кызыга, тик аларны тел белмәү туктата. Шуннан соң алар үзләреннән-үзләре телне өйрәнә башлый. Андый балалар бездә дә булды. Алар марттан бирле тел белгечләре белән эшләделәр. Әйтик, Зәринә Шакирҗанова татарча бер сүз дә белми иде, ләкин ул театрга үлеп гашыйк. Ул бөҗәк булып уйнарга да, хәтта берни уйнамаска да риза, аңа театр исен иснәү дә рухи рәхәтлек бирә. Зәринә Резеда Сәлахова белән бик нык эшләде. Һәм спектакльдә төп рольне камил дәрәҗәдә диярлек тамашачыга җиткерде. Шәһәр мэры Илсур Метшин: «Киләчәктә Казанның һәр районында «Апуш» театр студиясе булырга тиеш», – дип әйткән иде. Проект башланганга әле ярты ел гына узды, инде өч мәдәният үзәгендә («Сәйдәш», «Ленин» һәм «Чулпан») өч студия ачылды.

:: Казанда балалар шөгыльләнергә мөмкин булган сәнгать учаклары күп. «Апуш» студиясенең үзенчәлеге нидә?

– Беренчедән, биредә барлык дәресләр дә татар телендә алып барыла. Арада телне камил дәрәҗәдә белмәүчеләр дә бар, андый вакытта, әлбәттә, аңлатабыз, сүзләрне тәрҗемә итәбез. Һәм моның нәтиҗәсен дә күрәбез. Студиягә йөрүче бер баланың әнисе: «Минем кызым барысын да аңлый, тик татарча сөйләшми иде. Берике айдан ул татарча сөйләшә башлады», – диде. Димәк, ул үз өстендә эшли. Һәм татарча аралашу акрынлап гадәткә керә. Студиядә рус мәктәпләреннән килүче балалар да шөгыльләнә. Икенчедән, бу түләүле студия түгел. Барлык чыгымнарны Казан мэриясе үз өстенә ала.

:: Кастинглар быел үзенчәлеклерәк булды шикелле. Беренчедән, Казаннан гына түгел, районнардан да килүчеләр бар иде. Икенчедән, кастинг узган балалар тагын бер атна сыналды.

– Юк, мартта узган кастингта да Балтач, Арча, Лаеш районнарыннан килүчеләр булды. Алар бүген дә студиягә теләп йөри. Сынауга килгәндә, без аларны бер атна буе сынамадык, ә мин бер атна буе уйладым. Кастингта шигырь сөйләтеп кенә, баланың барлык сәләтен аңлап булмый, аны эш барышында карарга кирәк. Ахырдан барыбер балаларның барысы да диярлек калды. Бары тик яше җитеп бетмәү сәбәпле генә китүчеләр булды. Сентябрьдә узган кастингларда барлыгы 150дән артык бала катнашты. Бер кастингтан икенчесенә кадәр аралыкта кызыксыну бик нык арта. Әти-әниләргә дә, балаларга да рәхмәт. Балалар да шушында йөрүне башка илгә эләккән кебек кабул итәләр. Алар материалны бертигез дәрәҗәдә тотып алалар. Гомумән, «Апуш»ка йөрүче барлык балалар да бик дәртле, тырыш. Кайберәүләр, бәлки, безне әзер балалар гына алалар, дип уйлап ялгышырга да мөмкин. Ул сүз белән берничек тә килешә алмыйм. Аларның шушы юнәлештә сәләтләре бар. Аны үстерергә, ачарга кирәк. Студиядә балаларның сәләтен ачып, аларга юл күрсәтү мөһим. Кайбер әти-әни: «Минем балам аралашучан түгел. Сез аны ачыгыз әле», – дип килә. Ә бәлки, балага ул бөтенләй кирәкмидер? Аның холкы шундыйдыр һәм тормышта бөтенләй башка юнәлеш сайларга телидер? Мин мәҗбүриләү яклы түгел.

:: Баланың сәләтен ачу өчен нинди ысуллар кулланасыз?

– Балалар төрле булган кебек, сәләтләре дә төрлечә ачыла, чөнки кайбер бала бик нык ачылып китә. Әлбәттә, аны күрүдә, ачуда безнең үз тоемлавыбыз, тәҗрибәбез бар. Киләчәктә аның органикасы бармы, юкмы, табигыйлеген ача аламы, әллә билгеле бер калыпларга салынганмы? Шуны күзәтәбез. Кайбер балалар янып, чәчрәп тора, җырлый, бии, тик ул берничек тә үзгәрми. Һаман бер урында тора, чөнки ул үзен «булган» дип саный. «Сәйдәш»кә килүче балалар арасында андыйлар бик күп иде. Аларны бик нык «сындырырга» туры килде. Ә икенчеләре, киресенчә, акрынлап ачыла һәм канатланып китеп, үсәләр. Ниндидер мөмкинлекләр ачылып, үзләрен күрсәтәләр, дәлиллиләр.

:: Студиянең эчке кухнясын да бераз ачсагыз иде.

– Студиядә дисциплина буенча дәресләр бирелә. Актерлык осталыгы, сәхнә теле, сәхнә хәрәкәте һәм вокал. Бирегә кечкенәләр һәм зурлар төркеме йөри. Атнасына 9 сәгать белем алалар. Һәм безнең алдыбызда торган бурыч – елына ике спектакль кую. Яки ул бер спектакль һәм тематик кичә дә була ала. Мәсәлән, бу юлы «Сәйдәш»тә шундыйрак юнәлештә эшләячәкбез. «Чулпан» мәдәният үзәгендә спектакльләребез мюзикл юнәлешендә куелачак. Шуңа күрә монда балаларны алганда күбрәк җыр белән сынадык, биюгә игътибар бирдек. Премьералар исә «Чулпан»да – 22 декабрьгә, «Ленин» мәдәният сараенда 18–19 гыйнварга билгеләнгән.

:: Мартта тупланган балалар белән сез бер ай эчендә «Апушның тылсымлы төшләре» спектаклен чыгардыгыз. Бу – искиткеч зур хезмәт. Ничек тәвәккәлләдегез?

– Әгәр миңа: «Юк, булдыра алмыйсың», – дип әйтәләр икән, ничек итсәм итәм, мин булдырам. Вәгъдә биргәнмен икән, аны эшләмәүне күз алдыма да китерә алмыйм. Сиңа шундый зур мөмкинлек бирелгән икән, сынату мөмкин түгел. Вакыт никадәр кысан булса, эшчәнлегем шуның кадәр арта гына. Минем холкым шундый. Һәм, әлбәттә, остазлар бик көчле.

:: Аларны нинди сыйфатлары буенча сайладыгыз?

– Аларның тәҗрибәләре һәм кешелеклелек сыйфатлары буенча сайладым. Һәм, әлбәттә, балалар белән эшли алулары бик мөһим иде. Резеда Сәлахова, Алмаз Сабирҗанов, Сәлимә Әминова, Миләүшә Шәйхетдинова, Зөлфия Вәлиева, Ренат Мифтахов... Алар татар балалар театры юнәлешендә эшләргә тели. Без барыбыз да уртак максатлар һәм хыял белән яшибез.

:: Ярдәм һәм мөмкинлекләр зур булса да, бер генә эштә дә авырлыкларсыз булмый. Сезнең эштә дә бардыр?

– Мин әлегә ниндидер авырлыклар күрмәдем, чөнки монда барлык кешеләрнең дә теләкләре зур: остазлардан башлап әти-әниләргә кадәр. Мин шуңа игътибар итәм: нинди генә эшкә тотынсак та, барысына да юллар тиз генә ачыла. Иң мөһиме – балаларның көче һәм теләге булсын. «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә шөгыльләнүче балалар искиткеч. Алар иркенлек тапты. Кыска вакыт эчендә спектакль чыгару аларны чыннан да чыныктырды. Мин аларга ышандым.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Кайсыгызның кулы җылы?

ЯШӘҮ ЯМЕ – САБЫЙЛАРДА

Мөслим

Мөслим районының Күбәк авылында гомер итүче Ильфира һәм Ирек Камаловлар үз балалары янына тагын 6 сабыйны сыендырган. Мөгаен, ятимнәрне өч яшенә җитмичә вафат булган уллары хәсрәтен аз гына булса да киметү өчен алганнардыр. Ә бит заманында гаилә башлыгы, улымны авыруыннан коткарам дип, контракт төзеп, хәрби операциягә китә.

– Улымның йөрәгендә авыру бар иде. Операция өчен акча күп кирәк. Ә бездә аның кадәр юк. Нишләргә соң дип озак уйландым. Ул чакта мин хокук саклау органнарында эшли идем. Үзем сорап, Чечняга киттем. Янәсе, акча эшлим дә улымны коткарам. Шулай итеп, дүрт тапкыр барып кайттым. Ничек кенә тырышсам да, Илгизне яшәтә алмадык. Үзем дә ничек исән йөргәнмендер, шаккатам. Юкса иртән бергә чәй эчкән егетләр кичкә исән кайтмый иде. Мине, мөгаен, алып үстерәчәк балаларым яшәткәндер. Мин бу тормышта күпне күрдем. Бертуган абыем Илһам, хатынымның абыйсы Ильмир әфганчылар иде. Минеке – монда кайткач, хатынымныкы шунда үлде. Чечняда күргәннәремне сөйләү җиңел түгел, – дип искә ала Ирек абый.

Аның эше җиңел булмый. Кайчагында, исән калсам, 20 бала алып үстерер идем, дип тә әйткәли. Әнә шул сүзләре кабул була аның. Бөтен балалары бергә җыелгач, 20гә тулалар инде.

Беренче ятимнәрне алар 2010 елда барып ала. Аларның өйләренә бертуган өч бала кайта. Бала алу теләге зур була, хәтта олы малайның күзләре күрмәвенә дә исләре китми. Мөгаен, терелтербез дигән теләкләре зур булгандыр. Шулай була да, төрле табибларга йөртеп, күзенә операция ясатып, сабыйны савыктыралар.

Шулай бер-бер артлы өйгә сабыйлар кайтып кына тора. Аларның саны алтыга җитә. Камаловлар гаиләләренә инде үскән сабыйларны алырга тырыша. Кечкенәләрне аякка бастырыр өчен көч тә кирәк, гомер дә, ди алар.

– Үз балаларымны кадерләп, яратып үстерә алмадым. Гел эштә идем. Менә болар белән мәш киләм, – ди Ирек абый.

Гаилә зур булгач, мәшәкате дә күп. Алар яшерми, берсен укырга илтәсе, икенчесен – бакчага. Ризык та күп кирәк. Ирек абый әйтүенчә, алар вакланып тормый. Бөтен кирәк-яракны күп итеп алып куя. Ризыкны килолап түгел, тартмалап алалар икән.

Камаловлар элек абзар тутырып мал тоткан. Соңрак аларны бетереп, каз-үрдәккә күчкәннәр. Быел исә үрдәк кенә алганнар. Ильфира апа шулар белән мәш килә. Ирек абыйның исә яратып башкарган эше бар. Ул инде күп еллар умартачылык белән шөгыльләнә. Бал кортларын сабыйлар да үз иткән. Берсе дә куркып тормый.

– Ирек абыең шулар белән күңеленә ял таба. Мин монда кияүгә килгәндә умарталар бар иде инде. 34 ел буе тотабыз. Өй каршыбызда буш торган урын бар иде. Умарталар шунда тора. Мин үзем кортлардан бик курыксам да, өйдә кеше булмаганда аерылган күчне җыеп ала беләм, – ди Ильфира апа.

Балалар да кул арасына керә башлаган. Эштән курыкмыйлар, ди Ирек абый.

– Балны алар белән бергә аертабыз. Булышкалап торалар. Олыраклары минем белән ярминкәгә дә йөри. Күрсәгез иде сез аларны! Шулкадәр яратып йөриләр! Ярминкәгә барасы көнне иртәнге өчтә торып әзерләнәбез. Балаларга сату эше бик ошый, – ди Ирек абый. – Аллага шөкер, быел бал уңышы сөендерде. Икенче елга умарта санын арттырырга дип торабыз. Балымны бер алган кешеләр янә сорап килә. Яраталар. Кеше ошаткач, безгә дә рәхәт. Кәрәзлесен дә, литрлап та сатабыз. Баштарак 3 литрлы банкага 1500 сум сорый идек. Хәзер бәя дә төшә инде. Безгә акчасы түгел, рәхмәте кирәк.

Рәхмәт дигәннән, Камаловлар ул сүзгә күмелеп яши. Ятим сабыйларның җылы сүзләре, әтием-әнием дип торулары да картаерга ирек бирми үзләренә. Шул сабыйлар белән гомер узганын да, баш авыртканын да, аяк сызлаганын да сизмиләр икән. Арысалар да, рәхәт ару, диләр үзләре.

– Күңелдә тагын әллә никадәр сабый сыйдырырлык урын бар. Аларның әтием-әнием диюләренә эрим дә китәм инде. Тик яшь кенә бара. Ничек тә шушы алган сабыйларны аякка бастырасы, аларны тормышка әзерләп калдырасы иде. Арада бит авырулары да бар. Алары өчен бигрәк тә борчылабыз, – ди Ильфира апа. – Инде үзебезнең дә оныклар үсеп килә. Ике балабыз эне-сеңелләрен үз итеп яратып тора. Алар бергә бик дус-тату. Берберләре өчен нишләргә дә белмиләр. Ә безнең бер генә теләк – исән булсыннар!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6715 данә
Гомуми тираж – 15318 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 349

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+